**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күлле-Киме авыл җирлеге Күлле-Киме торак пунктында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

"24" ноябрь 2025 ел. № 2

2025 елның 20 мартындагы « Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ номерлы Федераль законының 45, 69 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Күлле-Киме авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Күлле-Киме авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №109 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең Күлле-Киме торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Күлле-Киме авылы территориясендә 2026 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең Күлле-Киме авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Авыл территориясен төзекләндерү (үләннәрне чабу һәм хезмәтләр өчен түләү, эш һәм хезмәт өчен түләү)

2) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (урамнарны кардан чистарту, эш һәм хезмәтләр өчен түләү)

3) Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм подстанция мәйданчыкларын, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуын һәм яктырткычлар сатып алу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү)

4) Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, материаллар сатып алу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү)»

5) Җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, торак пункт чикләрендә урнашкан гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына кермәгән җәяүлеләр өчен җир өстендәге кечү юлларын ремонтлау (күпер ремонты, материаллар сатып алу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү)

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең Күлле-Киме авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күлле-Киме авыл җирлегенең мәгълумат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Күлле-Киме авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълумат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы Гиниятов И.С.